Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советы
КАРАРЫ

12 март 2020 ел №187

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре башлыгының 2019 елгы эшчәнлек нәтиҗәләре һәм 2020 елга бурычлар турында хисабы

Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре башлыгы Т.Д. Нагумановның 2019 елгы эшчәнлек нәтиҗәләре һәм 2020 елга бурычлар турында хисабын тыңлап фикер алышканнан соң, Әлмәт шәһәр Советы шәһәр башлыгының үз вәкаләтләрен «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы, Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә гамәлгә ашыруын билгели.

Шәһәр башлыгы эшчәнлеге халыкның тормыш сыйфатын алга таба да яхшыртуга һәм шәһәр инфраструктурасын үстерү өчен уңай шартлар тудыруга юнәлдерелде.

Елның төп казанышлары: «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе», «Татарстан Республикасының иң төзек торак пункты» республика конкурсларында җиңү.

Шәһәр Советы шәһәр башлыгының хисап чорында Әлмәт шәһәрнең социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүен билгеләп үтә.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Уставы нигезләмәләре нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре башлыгының 2019 елгы эшчәнлек нәтиҗәләре һәм 2020 елга бурычлар турында хисабын игътибарга алырга.
2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үземдә калдырам.

Шәһәр башлыгы Т.Д. Нагуманов